**Гафиятов, Атлас. Халык белән бергә / А. Гафиятов // Идел. – 2020. – № 1 (364). – С. 11-13**

Идел
TATMEDIA
16+

Атлас Гафиятов,
«Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире,
Татарстанның атказанган матбугат хезмәткәре.

# ХАЛЫК БЕЛӘН БЕРГӘ

**2020 елның 22 гыйнварында «Татарстан яшьләре» газетасының чыга башлавына 100 ел тула. Быел, белгәнебезчә, республикабыз оешуга да бер гасыр. Менә шушы ике дата ниндидер символик мәгънәгә ия сыман. Ни генә булмасын, шушы вакыт эчендә газета халкыбыз тормышында (республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез өчен дә) искиткеч зур роль уйнады, дип әйтә алабыз.**

22 гыйнварда “Татарстан яшьләре” газетасының чыга башлавына да бер гасыр тулды. РКСМның, ягъни комсомолның Казан губерна башкарма комитеты буларак чыга башлаган басма “Кызыл яшьләр” дип аталаган. Ә 1949 елдан 56га кадәр ул “Яшь сталинчы” исеме астында, ә 1956 елдан башлап бүгенгәчә “Татарстан яшьләре” буларак дөнья күрә башлый. Газета чыга башлавының беренче елларыннан алып хәзерге көннәргә кадәр әдәбият-сәнгать мәсьәләсенә зур игътибар бирә, язучыларның иҗатын актив пропагандалый. Ул безнең халкыбызның гына түгел, хәтта читтә яшәүче милләттәшләребезнең дә милли үзаңын формалаштыруда зур роль уйный. Газетаның тарихы белән сез “Идел” журналында Атлас Гафиятов мәкаләсен укып таныша аласыз.